ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1 2018 елның 10 гыйнвары

Авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе һава киңлеген файдалануның федераль кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 11 мартындагы 138 номерлы карары, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын яңа кушымта итеп бирелгән редакциядә расларга.

2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Түбән Кама шәһәре территориясе өстендә авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга рөхсәт бирү буенча Административ регламентны раслау турында» 2016 елның 08 июнендәге 968 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 10 нчы гыйнвар
1 нче номерлы карары белән расланган
кушымта

Авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
Административ регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – хезмәт күрсәтү, муниципаль хезмәт күрсәтү).

1.2. Муниципаль хезмәт алучылар: билгеләнгән тәртип буенча һава киңлегеннән файдалану буенча (һава киңлегеннән файдаланучылар) эшчәнлекне гамәлгә ашыру хокукы бирелгән физик яисә юридик затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүче) (дәүләт хакимияте органнарыннан тыш).

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы - Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлеге (алга таба – Бүлек).

1.3.1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты урнашкан урын: Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 12 нче йорт.

Эш графигы:

- дүшәмбе - җомга: 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр;

- шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Белешмә телефоны: 8(8555) 42-50-50.

Бүлекнең урнашкан урыны: Түбән Кама шәһәре, Мәктәп Бульвары ур., 2а йорты.

Эш графигы:

- дүшәмбе - җомга: 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр;

- шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Белешмә телефоны: 8(8555) 41-56-41, электрон почта: Nk.transport@yandex.ru.

1.4. Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат түбәндәгеләрдән алынырга мөмкин:

- Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында http://www.e-nkama.ru;

1.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Түбән Кама муниципаль районы сайтында урнаштырыла.

1.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- 1997 елның 19 мартындагы 60-ФЗ номерлы Россия Федерациясе һава кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 24.03.1997, № 12, 1383 ст.) (алга таба - Һава кодексы);

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 06.10.2003, № 40, 3822 ст.) (алга таба - 131-ФЗ номерлы Федераль закон);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.) (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе һава киңлегеннән файдалануның федераль кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 11 мартындагы 138 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы 05.04.2010, № 14, 1649 ст.) (алга таба - РФ Хөкүмәтенең 138 номерлы карары);

- РФ Оборона министрының 136 номерлы, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 42 номерлы, Россия авиация-космик агентлыгының «Россия Федерациясе һава киңлегендә очышларның федераль авиация кагыйдәләрен раслау турында» 2002 елның 31 мартындагы 51 номерлы («Российская газета», 149-150, 13.08.2002) боерыгы белән;

- РФ Транспорт министрлыгының «Россия Федерациясе һава киңлеген планлаштыруны һәм алардан файдалануны оештыру» Федераль авиация кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 16 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгы белән (Россия газетасы, № 73, 04.04.2012) (алга таба - РФ Транспорт министрлыгының 6 номерлы боерыгы белән);

- РФ Транспорт министрлыгының «Тыелган зоналарны билгеләү турында» 2016 елның 9 мартындагы 48 номерлы (хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 14.04.2016) (алга таба - РФ Транспорт министрлыгының 48 номерлы боерыгы) боерыгы белән;

- Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын

эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карары (алга таба - 1491 номерлы Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карары);

- Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән;

- Түбән Кама муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 номерлы карары белән расланган «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе нигезләмәсе (алга таба - БК турындагы нигезләмә).

1.7. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

а) авиация эшләре - авыл хуҗалыгында, төзелештә, әйләнә-тирә мохитне саклау, медицина ярдәме күрсәтү өчен һәм башка максатларда гражданнар һава суднолары очышын файдаланып башкарыла торган, Россия Федерациясендә Транспорт министрлыгы билгели торган исемлеккә кергән эшләр.

б) аэростат – күтәрү көче аэростатик яки бер үк вакытта аэростатик һәм аэродинамик принципларга нигезләнгән очу аппараты;

в) пилотсыз очу аппараты - бортта пилотсыз (экипажсыз) очыш башкаручы һәм очышта автомат рәвештә, идарә пунктыннан оператор яки күрсәтелгән ысуллар кушылмасы белән идарә ителә торган очу аппараты;

г) техник хата - муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматлар (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе) документтагы мәгълүмат нигезендә кертелгән мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуның ише хата).

Әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) астында муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы 2 пункты). Сорату стандарт бланкта (1 нче кушымта) тутырыла.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү атамасы | Авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 11 мартындагы 138 номерлы карары |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә органының башкарма-боеру органы атамасы | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлеге | Башкарма комитет турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | 1) авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәтне җибәрү (бирү) (2 нче кушымта);<br>2) авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронави- | |

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| | гация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә җибәрү (бирү) (3 нче кушымта) | |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты. гариза бирү көнен дә кертеп, 10 эш көне тәшкил итә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләрнең тулы исемлеге, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 1) һава судносының тибын, дәүләт (теркәү) тану билгесен, завод номерын (булган очракта) һәм кемнеке булуын, авиация эшчәнлегенең башкару чорын һәм урынын күрсәтеп, әлеге регламентка 1 нче кушымта нигезендә рәсмиләштерелгән кәгазь чыганакта документ рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтүгә гариза;<br>2) гариза бирүче юридик зат булса, устав;<br>3) гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ;<br>4) әлеге регламентның 1.2 пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ;<br>5) әлеге регламентның 1.2 пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, аның вәкаләтләрен раслаучы документ;<br>6) башкару тәртибе проекты (эшчәнлек төре буенча):<br>-авиация эшләре яисә авиация эшләренең белдерелгән төрләрен үтәү үзенчәлекләрен үз эченә алган очышлар башкару буенча җитәкчелек бүлеге; | Россия Федерациясе Һава кодексы |

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
| --- | --- | --- |
| | - сикерү вакытын, урынын, биеклеген һәм һава судносының күтәрелү санын күрсәтеп, парашютчыларны десантлау;<br>- 50 метрдан артык биеклеккә күтәрелгән очракта, бәйле аэростатларның күтәрелү вакытын, урынын, биеклеген күрсәтеп, бәйле аэростатларның күтәрелешләре;<br>- һава судносының күтәрелү вакытын, урынын, биеклеген һәм санын күрсәтеп, һава судноларының күрсәтмәле очышлары;<br>- бәйле аэростатларны күтәрү вакытын, урынын, биеклеген һәм санын күрсәтеп, пилотсыз очу аппаратлары очышы;<br>-күтәрелү (утырту) вакытын, урынын һәм санын күрсәтеп, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга очып төшү (очып күтәрелү);<br>7) билгеләнгән авиация эшләрен башкаруга өченче зат белән шартнамә;<br>8) һава судноларының билгеләнгән типларын очыш һәм техник эксплуатацияләүгә кертелгән авиация персоналы составына керүче гражданнарның шәхесен раслаучы документлар күчермәләре;<br>9) очу өчен яраклылык сертификаты (очуга яраклык турында таныклык) һәм һава судносын Россия Федерациясе граждан һава суднолары дәүләт реестрына кертү;<br>10Россия Федерациясе Һава кодексының 133 статьясы | |

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| | нигезендә өченче затлар алдында һава судносының җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерүне раслаучы документлар күчермәләре;<br>11) авиация эшләре башкарылган очракта, Россия Федерациясе Һава кодексының 135 статьясы нигезендә авиация эшләре вакытында эксплуатантның җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерүне раслаучы документлар күчермәләре;<br>12) Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән килештерү;<br>13) Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча хәбәрнамәсе;<br>14) Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре федераль хезмәте идарәсе хәбәрнамәсе;<br>15) «Һава хәрәкәтен оештыру буенча дәүләт корпорациясе» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татаэронавигация» филиалы хәбәрнамәсе.<br>2. Дәүләт авиациясенә караган мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан авиация эшләрен башкаруга рөхсәт алу өчен:<br>- әлеге регламентка 1 нче кушымта нигезендә рәсмиләштерелгән кәгазь чыганакта документ рәвешендә муниципаль хезмәт күрсәтүгә гариза;<br>- билгеләнгән һава судносының эксплуатациягә яраклы булуын раслаучы документ (һава судносы формулярыннан эксплуатациягә яраклылык турында язма белән күчермә); | |

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| | - мөрәҗәгать итүче базасында парашют-десант хезмәте оештыру турында нигезләмә (килешенү буенча);<br>- 50 метрдан артык биеклеккә күтәрелгән очракта, бәйле аэростатларның күтәрелү биеклеген, вакытын, урынын күрсәтеп, бәйле аэростатларны күтәрү тәртибе проекты.<br>Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бланкын Бүлеккә шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм кушымта итеп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга мөмкин:<br>- шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);<br>- тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Искәрмә: әлеге административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар гариза бирүче тарафыннан расланган күчермәләр рәвешендә үтәүгә планлаштырылган авиация эшләре төренә бәйле рәвештә тапшырыла (гаризалардан тыш). Күрсәтелгән | |

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| | документларның күчермәләрендә гариза бирүче тарафыннан мондый документның һәр битендә «күчермә дөрес» билгесе, расшифровкалау белән имза, мөһер (юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр өчен) куела. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары, башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма. | - | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда аларны килештерү хезмәт күрсәтү өчен | Аларның территорияләре өстендә авиация эшләре, парашют сикерүләре, һава судноларының күрсәтмәле очышлары, пилотсыз очу аппаратлары очышы, бәйле аэростатлар | |

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| кирәк булган һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | күтәрү, аэронавигация мәгълүматы документларында басылмаган, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга утырту (күтәрелү) планлаштырылган Түбән Кама муниципаль районы җирлекләренең башкарма-боеру органнары хәбәрнамәсе. | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) тиешенчә булмаган зат тарафыннан документлар бирү;<br>2) гаризада һәм гаризага кушымта итеп бирелә торган документларда алдан сөйләшенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлатмый торган җитди зарарланулар бар;<br>3) Документларны тиешле булмаган органга тапшыру | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>2) әлеге регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән дәүләт органнарының үтәлүне килештерү нәтиҗәләре буенча тискәре бәяләмәләр алу | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| алу нигезләре | | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләүне алу тәртибе, күләме һәм аның алыну нигезләре, мондый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булган очракта, муниципаль хезмәт алуга гариза бирү - 15 минуттан артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы соратуын теркәү срогы | Гариза кергәннән соң бер көн эчендә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган урыннарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм кабул итү урынына таләпләр, шул исәптән күрсәтелгән объектларның инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидларның алардан файдалана | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм урыннарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтүче белгечкә тоткарлыксыз керүе тәэмин ителә (урынга җайлаштырылган керү, аларның чикләрендә уңайлы хәрәкәт итү һәм чыгу юлы).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль һәм | |

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
| --- | --- | --- |
| алуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | текстлы мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең ачыклыгы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, КФҮдә, КФҮнең читтән торып эш урыннарында муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>- муниципаль хезмәт күрсәтү урынының җәмәгать транспорттыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>- мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган белгечләрнең, шулай ук урыннарның кирәкле санда булуы;<br>- Интернет челтәренең, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының мәгълүмати ресурсларында муниципаль хезмәт күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән билгеләнә:<br>- мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең мөрәҗәгать итүчегә карата әдәпсез, | |

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| | игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр гына үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Аралашу озынлыгы регламент белән билгеләнә.<br>КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтелми.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан 8(8555) 41-56-41 телефоны буенча алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә алу тәртибе турында консультацияне интернет-кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша алырга мөмкин.<br>Закон белән электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү каралган очракта, гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша бирелә http://uslugi.tatar.ru/ яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша http://www.gosuslugi.ru/ | |

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук КФҮдә, КФҮнең читтән торып эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы.

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

2) гариза кабул итү һәм теркәү;

3) тапшырылган документларны карау

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге блок-схемасы 4 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша һәм (яисә) электрон почта аша муниципаль хезмәтне алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен Бүлеккә мөрәҗәгать итә.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документациянең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация бирә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр, кисәтүләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы зат аша Бүлеккә авиация эшләре, парашют сикерүләре башкаруга, бәйле аэростатлар күтәрүгә, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга утыртуга (күтәрелүгә) рөхсәт бирү буенча язмача сорату бирә һәм әлеге регламентның 2.5. пункты нигезендә документлар тапшыра.

Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бүлеккә электрон почта аша яисә Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Гаризалар кабул итүче Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү;

- мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерү (ышанычнамә буенча гамәл кылган очракта).

Кисәтүләр булмаган очракта, Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- соратуны кабул итү һәм махсус журналда теркәү;

- мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү датасы, беркетелгән керү номеры, муниципаль хезмәтне башкару датасы һәм вакыты турында тамга белән сорату күчермәсен тапшыру.

- Башкарма комитет җитәкчесенә карау өчен гариза юллау.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, документларны кабул итүче Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар барлыгы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны аңа кайтара.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар 15 минут дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза яисә мөрәҗәгать итүчегә кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм гаризаны Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Бүлек белгече материалларны карый, әлеге регламентның 2.5 пунктында каралган документларның барлыгын тикшерә, тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуын тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң биш эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тикшерелгән гариза һәм аңа кушымта итеп бирелә торган документлар.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. 3.4 пунктында каралган процедуралар нәтиҗәләре буенча Бүлек белгече рөхсәт бирү турында карар кабул итә яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хәбәрнамә әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе:раслауга җибәрелгән документ проекты.

3.5.2. Башкарма комитет җитәкчесе рөхсәт кәгазенә яисә баш тарту турында хәбәрнамәгә кул куя.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган документ.

3.5.3. Бүлек белгече, имзаланган рөхсәтне алгач, мөрәҗәгать итүчегә билгеләнгән ысул белән хәбәр итә һәм мөрәҗәгать итүче килгәч, бирелгән рөхсәтләрне исәпкә алу журналына бу хакта язуны кертеп, рөхсәтне бирә (6 нчы кушымта). Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарткан очракта, гариза бирүчегә имзаланган хәбәрнамәне почта аша җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

15 минут дәвамында - мөрәҗәгать итүче шәхсән килгән очракта;

алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында, почта юлламасы белән җавап җибәрелгән очракта.

Процедуралар нәтиҗәсе: бирелгән рөхсәт яки җибәрелгән баш тарту турында

хәбәрнамә.

3.6. Техник хаталарны төзәтү.

3.6.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

- техник хатаны төзәтү турында гариза (5 нче кушымта);
- мөрәҗәгать итүчегә техник хата булган муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;
- юридик көчкә ия, техник хата булуын дәлилләүче документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән, электрон почта аша), яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталы аша бирелә.

3.6.2. Идарә белгече техник хатаны төзәтү турында гариза кабул итә һәм кушымта итеп бирелгән документлар белән гаризаны терки.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә карауга юнәлтелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.6.3. Бүлек белгече документларны карый һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен имза куйдырып алып, мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән төзәтелгән документны бирә яисә гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта аша) техник хата булган документның төп нөсхәсен Бүлеккә тапшырганда документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алганнан соң өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (юнәлтелгән) документ.

## IV. Муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне үткәрүне, җирле үзидарә органының вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып, проектларга виза салу тора;

2) билгеләнгән тәртиптә эш башкаруга тикшерүләр оештыру;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлүен билгеләнгән тәртиптә тикшереп тору.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр яисә мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндәге гамәлләрне контрольдә тотуны тормышка ашыру һәм карар кабул итү максатларында Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контроль Башкарма комитет җитәкчесе яисә ул вәкаләт биргән зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре нигезләмәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Башкарма комитет җитәкчесе мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап чыкмау өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) әлеге Регламентның III бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту, муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу аша башкарыла.

## V. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәт алучылар Башкарма комитетка муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Башкарма комитет хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр билгеле бер тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы соратуын теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган документларны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Түбән Кама муниципаль районының башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган өстәмә түләүләр таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда алар җибәргән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять кәгазь чыганакта язма формада яки электрон формада бирелә.

Шикаять Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтыннан файдаланып почта аша җибәрелә ала (http://www.e-nkama.ru), шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау вакыты - теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдән, яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргәндә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта шикаять биргәндә - теркәлгән көннән биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яисә муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә мөрәҗәгать итүченең – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүмат, исеме, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле элемтә өчен телефоны номер(лар)ы, электрон почта адрес(лар)ы (булган очракта) һәм почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) аның нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән гариза бирүче риза булмаган дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән шартларны раслаучы документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аны биргән муниципаль хезмәт күрсәтүне алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән, кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән төгәлсезлек һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында алу каралмаган акчаны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару рәвешендә, шулай ук башка формалада да;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә аны карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат кичекмәстән булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә.

Авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышла-

рын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына
1 нче кушымта
(Форма)
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенә

______________________________________
____________________________________-ннән
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (мөрәҗәгать итүченең вазыйфасын күрсәтеп - юридик заттан гариза биргәндә)

______________________________________
(физик затның шәхесен раслаучы документ белешмәләре)

______________________________________
юридик затның оештыру-хокукый формасын күрсәтеп тулы исеме

______________________________________
(яшәү урыны/урнашу адресы)

______________________________________
______________________________________
телефон:__________________,
факс______________
E-mail: ________________________________

Авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирү турында сорату

________________________________________________________________ өчен
(һава киңлеген файдалану эшчәнлеге төре)
_____________________ территориясе өстендә һава киңлеген файдалануга рөхсәт бирүегезне сорыйм.
һава судносы:
тибы__________________________________________________________________
дәүләт (теркәлү) тану билгесе_______________________________________________
завод номеры (булса)_______________________________________________________

_________________________территориясе өстендә һава киңлеген файдалану вакыты:

башы________________________________, ахыры___________________________________.

___________________территориясе өстендә һава киңлеген файдалану урыны (файдалану өчен планлаштырылган утырту урыннары):
_______________________________________________________________________________,
___________________территориясе өстендә һава киңлеген файдалану вакыты
(төнге/көндез)
Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны беркетәм:
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында, күрсәтелгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм тикшерүгә ризалык бирәм.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта документ формасында шәхсән тапшыруыгызны/электрон почта аша электрон документ рәвешендә җибәрүегезне/ «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, электрон документ рәвешендә тапшыруыгызны/телефон аша хәбәр итүегезне (кирәклесе астына сызарга) сорыйм.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм соратуны кабул итүдән баш тарту турындагы карарны кәгазь чыганакта документ формасында шәхсән тапшыруыгызны/электрон почта аша электрон документ рәвешендә җибәрүегезне /телефон аша хәбәр итүегезне (кирәклесе астына сызарга) сорыйм.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карарны кәгазь чыганакта документ формасында шәхсән тапшыруыгызны/электрон почта аша электрон документ рәвешендә җибәрүегезне/телефон аша хәбәр итүегезне (кирәклесе астына сызарга) сорыйм.

____________________ ____________________ ____________________
(число, ай, ел) (имза) (расшифровкалау)

| |
|---|
| Хезмәт билгеләре |
| Соратту кабул ителде:<br>Дата:<br>керү.N:<br>Ф. И. А.ис. һәм соратуны кабул иткән кеше имзасы |
| Рөхсәт бирелде<br>Дата: |

Авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен

башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына
2 нче кушымта
(Форма)

Авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт

«__» ___________20__ ел №__________________

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 11 мартындагы 138 номерлы карары һәм «Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмә белән расланган Россия Федерациясе һава киңлеген файдалану буенча федераль кагыйдәләрнең 49 пункты нигезендә рөхсәт бирә

_____________________________________________________________________________
(юридик затның исеме; физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
(урын/яшәү адресы): _______________________________________________________
дәүләт теркәве турында таныклык: ________________________________________
(серия, номер)
шәхесне раслаучы документ белешмәләре: __________________________________
(серия, номер)
_________________________________________________________________________ өчен
(һава киңлеген файдалану эшчәнлеге төре)
________________________территориясе өстендә һава киңлеген файдалану
һава судносы:
тибы_______________________________________________________________________
дәүләт теркәү (танып белү/хисап-тану) билгесе __________________
завод номеры (булганда) ____________________________________________________
________________территориясе өстендә һава киңлеген файдалану срогы:
_____________________________________________________________________________

Чикләүләр/искәрмәләр:
_____________________________________________________________________________

Рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты:

_______________________________________________________________

_____________________ ______________ _________________________

(вазыйфа) (имза) (расшифровкалау)

*әлеге рөхсәт Башкарма комитет бланкында рәсмиләштерелә

Авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына
3 нче кушымта
(Форма)

Авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә


«__» _________20__ ел

______________________________________________________________________
(юридик затның исеме; физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
______________________________________________________________________
(рөхсәт бирүдән баш тарту нигезе күрсәтелә)

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ____________________ | ____________________ |
| (вазыйфа) | (имза) | (расшифровкалау) |

Авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына
4 нче кушымта
(Форма)

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы



Авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына
5 нче кушымта
(Форма)

Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенә
___________________________________
_______________________________

техник хатаны төзәтү турында гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
________________________________________________________________________________

Язылган:___________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне сорыйм.
Түбәндәге документларны терким:
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Телефон: __________________________ E-mail: ______________________________

Дата___________ Имза______________________/________________________________

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:
электрон документны E-mail:____________ адресына җибәрү юлы белән;

________________________________________адресы буенча поста аша кәгазь чыганактагы таныкланган күчермә рәвешендә.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси мәгълүматның шәхси үзенчәлекләрен бетерү, блоклау, юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында, алар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп, автомат режимында үз ризалыгымны, шулай ук мин тәкъдим иткән затның ризалыгын раслыйм.

Раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм анда дөрес мәгълүматлар кертелгән.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша үткәрелгән сораштыруларда катнашуга ризалыгымны бирәм: ____________________.

| | | |
|---|---|---|
| ______________ | ________________ | ( ________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А.ис.) |

Авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына
6 нчы кушымта

1. Журналның титул бите:

Авиация эшләрен, парашют сикерүләрен, һава судноларының күрсәтмәле очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, бәйле аэростатларның күтәрелүен башкаруга, Түбән Кама муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә урнашкан, алар турында белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында күрсәтелмәгән мәйданчыкка очып төшүгә (очып күтәрелүгә) бирелгән рөхсәтләрне исәпкә алуның

______ номерлы журналы

_______ ел сакларга

Башланган: ____________

Тәмамланган:_________

| 2. Кире якның беренче бите: № п/п | Рөхсәтнең номеры/ датасы | Мөрәҗәгать итүченең исеме | Рөхсәт гамәлдә булу вакыты | Территория өстендәге һава киңлегеннән файдалану эшчәнлеге төре | Һава судносы тибы, дәүләт (теркәү) билгесе/исәп-тану билгесе, завод-номеры (булган очракта) | Рөхсәтне кулга алдым (имза Ф.И.А.ис., дата) | Чикләүләр/ искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |